**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кече Шилнә авыл җирлеге аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кече Шилнә авыл җирлегендәге Кече Шилнә авылының Ленин урамындагы 44 йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылындагы эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территориядә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кече Шилнә авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 1 февралендәге ПУ-76 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 06 апрель
№ ПУ-240